ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2024 г.Казань № 697-259/тп-2024

2025 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәрләренә газ куллана торган җиһазларны технологик тоташтыруга түләү күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне, аны транспортировкалау хезмәтләре күрсәтүгә тарифларны, газ кулланучы җайланманы газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләүләрне һәм магистраль газүткәргечләрдән капиталь төзелеш объектларына кадәр газны транспортировкалау өчен төзелүче һәм реконструкцияләнә торган газүткәргечләрне һәм табигый газ ятмаларыннан магистраль газүткәргечкә кадәр газны транспортировкалау өчен билгеләнгән газүткәргечләрне магистраль газүткәргечләргә технологик тоташтыру өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм (яки) аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1151/18 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2024 ел, №36-ПР утырыш беркетмәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ куллану җиһазларын газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү күләмен билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү күләме 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән гаризачылар категорияләренең газ куллану

җиһазларын тоташтырудан алынмый калган керемнәрен 7 891,120 мең сум күләмендә билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2024 № 697-259/тп-20224
карарына кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәрләренә газ куллана торган җиһазларны технологик тоташтыруга 2025 елга түләү күләме

| Тәртип саны | Мөрәҗәгать итүчеләрнең категориясе | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәрге аралык | Технологик тоташтыру өчен түләү күләме, сум. | |
|---|---|---|---|---|
| | | | НДС исәпкә алмыйча | НДС исәпкә алып<*> |
| 1. | Газ куллана торган җиһаздан проект буенча эш басымы 0,3 МПа артмаган газ бүлү челтәренә кадәрге, туры линия (иң аз аралык) буенча үлчәнә торган ераклык 200 метрдан артмау һәм торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча билгеләнгән тәртиптә расланган төбәк (төбәкара) программа, шулай ук халыкны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемасы нигезендә фәкать газүткәргечләр төзүне генә (траншеясыз ысул белән газүткәргечләр салу һәм газны редукцияләү пункты урнаштыру чараларын башкару зарурлыгыннан башка гына) күздә тоткан чаралар шарты белән, әлеге тоташтыру ноктасында (башка төр гаризачылар өчен) элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җиһазы сарыф итә торган газны исәпкә алып, бер сәгатьтә газ сарыф итүнең максималь күләме 5 куб.метрдан артмый торган. | 10 м кадәр (иң күбе) | 34 827,59 | 41 793,11 |
| | | 10 м дан артып, 20 м га кадәр (иң күбе) | 47 016,88 | 56 420,26 |
| | | 20 м озынрак | 72 557,48 | 87 068,98 |
| 2. | Газ куллана торган җиһаздан проект буенча эш басымы 0,3 МПа артмаган газ бүлү челтәренә кадәрге, туры линия (иң аз аралык) буенча үлчәнә торган ераклык 200 метрдан артмау һәм торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча билгеләнгән | 200 м кадәр (иң күбе) | 72 557,48 | 87 068,98 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәртиптә расланган төбәк (төбәкара) программа, шулай ук халыкны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемасы нигезендә фәкать газүткәргечләр төзүне генә (траншеясыз ысул белән газүткәргечләр салу һәм газны редукцияләү пункты урнаштыру чараларын башкару зарурлыгыннан башка гына) күздә тоткан чаралар шарты белән, әлеге тоташтыру ноктасында (эшкуарлык (коммерция) эшчәнлеге максатларында газ куллану нияте булган гаризачылар өчен) элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җиһазы сарыф итә торган газны исәпкә алып, бер сәгатьтә газ сарыф итүнең максималь күләме 15 куб. метрдан артмый торган. | | | |

<*> Мөрәҗәгать итүчеләр – физик зат булган очракларда

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге